СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«КАРМАЛКИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«КАРМАЛКА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

2025 елның 25 ноябре Кармалка авылы № 9

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 15 октябрендәге 8 номерлы карарына (07.11.2023 № 41, 06.06.2024 № 11, 08.07.2025 № 15 үзгәрешләр белән) үзгәреш кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән, гражданнарның аерым категорияләренә җир салымы буенча бирелә торган ташламаларны Россия Федерациясе Салым кодексы нормаларына туры китерү максатында, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 15 октябрендәге 17 номерлы карарына (07.11.2023 № 41, 06.06.2024 № 11, 08.07.2025 № 15 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3 пунктның дүртенче абзацын төшереп калдырырга.

2.Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Кармалка авылы, Геодезия ур., 38а йорт, (административ бина), Нагорная ур., 33 йорт (мәдәният йорты бинасы), Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru)бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Кармалка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе В.Д.Фатхутдинова